СЕЗНЕ ИШЕТӘЛӘР!
Рөстәм Миңнеханов эшмәкәрләр зарын тыңлады
> 2

УРМАН КИЛӘЧӘГЕ
Урман хуҗалыгы тармагына килүчеләргә дәүләт ярдәм итәчәк
> 2

АВЫЛ ИМАМЫ
«ВТ» укучыларының саладагы дин әһелләре турында язмалары
> 3

КУБОК – ӘЛМӘТТӘ!
Газетабыз турнирында узган елгы җиңүчеләрнең өчесе генә үз батырлыгын кабатлый алды
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 39 (28812) | Сишәмбе | 22 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Язгы ярминкәләр

Гыйбрәт алырлык хәлләр әледән-әле кабатланып тора. Пандемия чорында кирәксә-кирәкмәсә дә капчык-капчык он, ярма, тоз алып куючыларның балкон шүрлекләре бушап та өлгермәде, кибеттән карабодай, шикәр комы ташый башладык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

БАРЫБЫЗГА ДА ҖИТӘ

Ярминкәдә иртәнге биштән үк шикәр комына чиратка баскан олы яшьтәге танышымнан махсус кызыксындым. «Гаражда ике капчык шикәр комы бар барын. Тик, дөнья хәлен белеп булмый, запас эчне тишмәс», – ди. Ике кешелек гаиләгә ике елга җитәрлек шикәр комы! Күршесенең дүрт капчык шикәр комы булганда, гаҗәпләнәсе дә юк...

Сер түгел, сәүдә нокталарының күбесендә берничә ай дәвамында сату итәрлек мөмкинлекләре булса да, күбесе тиз арада бәяне күтәреп куярга ашыкты. Шуңа күрә Татарстанда язгы ярминкәләр башланып киткәч, халык җиңел сулап куйды дисәм, арттыру булмастыр. 19 мартта башкаланың һәр районында шаулап-гөрләп эшләп торган ярминкәләрендә шикәр комының бәясе 60 сум иде. Сатып алучыларны аңлап була: бу бит кибет киштәләрендәгедән ике тапкыр арзанрак!

«Казан» агропаркы сәүдә мәйданчыклары да шимбә иртәсендә ыгы-зыгыдан шаулап торды. Кайсы җиңел куларба тарткан, кайберләре машинасын сәүдә рәтләренә якынрак куймакчы. Башка еллардан аермалы буларак, сатып алучыларның күбесе шикәр комы, карабодай кебек бәяләре кинәт кенә күтәрелеп киткән продуктларны эләктереп калырга тырыша. Күз ачып йомганчы, су буе чират хасил булды.

Ярминкәгә Арча, Мамадыш, Кукмара, Лаеш районы хуҗалыклары, «Татагролизинг», «Майский» теплица комбинаты һәм башка эре җитештерүчеләр алып килгән ит, сөт, яшелчә, җиләк-җимешләрнең бәяләре чагыштырмача шактый арзан булу да сөендерә.

Бәяләр чагыштырмача түбән булса да, акча янчыгыңа карап, сайлап алу мөмкинлеге дә бар. Әйтик, «Майский» комбинаты тәкъдим иткән кыярның килограммын – 70, помидорны 110 сумнан сатып алырга була. Кукмара районы «Урал» хуҗалыгы бәрәңгенең килограммын 40 сумнан сатса, Арча районы «Шушмабаш» хуҗалыгы алып килгән сөтне 35 сумнан сатып алырга мөмкин иде. Ит, май, йомырка, яшелчәләрнең дә бәяләре чагыштырмача арзан.

– Карабодайның килограммы – 90 сум. Ит – 380 сум, йомырка – 70, онны 35 сумнан алдым, – дип шатлана Казанның Зәкиев урамында яшәүче күптәнге танышым Гөлсара Сәгыйтова.

Кукмара районы Сәрдекбаш авылында яшәүче Алсу Галиева шәхси хуҗалыгында дистәдән артык төрле продукция җитештерә икән. Борай онынан ясалган токмачны Казан халкы рәхмәтләр укый-укый ала. «Рамазан икмәге», печенье, прәннек кебек тәмле ризыкларны да яраталар», – ди алтын куллы Алсу ханым.

Ярминкәгә иң саллы күчтәнәчләр белән килгән Арча уңганнары турында аерым әйтмичә булмый. Арча районы хуҗалыкларында җитештерелгән азык-төлек, хәйрия өстәлләрен бизәп торучы сый-хөрмәтләре үзенә бер төрле тәмле булса, җыр-бию осталарының чыгышы ярминкә мәйданнарына бәйрәм төсмере бирә. Арча һәвәскәрләренең дәртле җырын, егет-кызларның очып-очып биюләрен күргәч, һич арттырусыз әйтәм, шактый өлкән яшьтәге бер апа, үзе дә сизмәстән, җилкенеп биеп китте. Аңа башкалар да кушылды. Мондый бәйрәм оештыручыларга ничек рәхмәтле булмыйсың?

Кукмара районы хакимияте башлыгы Сергей Димитриев сүзләренә караганда, район хуҗалыклары, авыл җирлекләре ярминкәгә күчтәнәчләрне 40 авыр йөк машинасына төяп килгән. Ярминкәдә алар Казан халкына 20 тонна бәрәңге, 3000 килограмм ит, меңнәрчә килограмм он, ярма һәм сөт продукцияләрен чагыштырмача арзан бәядән тәкъдим иттеләр.

Ел саен Казанда узган чаралардан аермалы буларак, быелгы ярминкәләрнең төп үзенчәлеге – шикәр комы һәм кайбер төр продукцияләргә су буе чират булу. Мондый хәл ярминкәләрне карап йөргән Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаровның да игътибарыннан читтә калмаган. Узган еллардагы ярминкәләрдә уртача 15–20 тонна шикәр комы сатылган булса, быел аның күләме 93 тоннадан арткан.

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, ярминкәләрдә 16 район, ике меңнән артык хуҗалык хезмәтчәннәре катнашкан. Казанда – 15, Яшел Үзән, Чаллы һәм Түбән Каманың икешәр сәүдә мәйданчыгында узган ярминкәләрендә башка еллардагы белән чагыштырганда дүрт-биш тапкыр артык күләмдә азык-төлек, шул исәптән ит, сөт, яшелчә, шикәр комы, башка төр продуктлар сатылган. Чагыштыру өчен берничә сан китерү дә җитә. Әйтик, узган елларда мондый ярминкәләрдә уртача 19–20 тонна бәрәңге сатылса, быел аның күләме 102 тоннага җиткән. 500 авыр йөк машинасына төяп, бик күп төрле азык-төлек алып килгәннәр. Ярминкәләр исә атнаның һәр шимбәсендә 23 апрельгә кадәр дәвам итәчәк.

Халыкны борчыган шикәр комына килгәндә, министрлыкта әйтүләренчә, махсус саклау урыннарында әлеге продукт яңа уңышка кадәр җитәрлек әзерләнеп куелган. Татарстан Президенты кушуы буенча, социаль оешмалар, ярминкәләр өчен өстәмә резерв та булдырылган. Башка төр продуктлар буенча да хәл тотрыклы, диләр.

Мондый ыгы-зыгылар каян килә соң? Интернетны күзәтеп баручылар хәтерлидер. Шикәр комы турында сүз барганда, берәү үзенең 7 тонна запасы белән мактанды. Билгеле, әлеге кеше бу кадәр шикәр комын үзе генә кулланмаячак. Андыйлар бәя күтәрелгәнне көтә. Кайбер җитештерүчеләр, арадашчылар һәм күпләп сатучылар да болганчык суда балык тотып калмакчы. Татарстан Премьер-министры урынбасары – икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов әйтүенчә, бәяләрне нигезсез күтәргән 40 оешмага карата тикшерү эшләре бара. Шикәр комы һәм кайбер башка төр продуктлар буенча ясалма ыгы-зыгы тудырырга омтылучыларга карата тиз арада тиешле чаралар да күреләчәк, ди икътисад министры.

Камил СӘГЪДӘТШИН

Балаларга сыену урыны табылган

Татарстан Донецк һәм Луганск республикаларыннан 50дән артык баланы кабул иткән. Мәгариф һәм фән министры урынбасары Алсу Әсәдуллина әйтүенчә, безгә алар махсус төркемнәр белән түгел, ә гаиләләре, әбиләре, өлкәнрәк туганнары белән килгән. Республикага балалар февраль ахырыннан кайта башлаган. Алар инде мәктәпләрдә, көллиятләрдә укый, балалар бакчаларына йөри. Донбасстан күченүчеләр Казанда гына түгел, районнарда да яши. Алар үзләренең туганнарына, вакытлыча яшәү урыннарына урнаштырылган. «Без мондый гаиләләр белән даими эшлибез. Кирәк булганда, психологлар, социаль хезмәткәрләр җәлеп итәбез. Волонтерлар – һәрвакыт алар янәшәсендә. Мондый авыр вакытларда алар балаларны кемгә караганда да яхшырак аңлый», – ди министр урынбасары.

Имтихан вакытында узачак

Төп һәм Бердәм дәүләт имтиханнары үз вакытында үткәреләчәк. Кайбер төбәкләрдә кәгазь җитмәү мәсьәләсе озакламый хәл ителәчәк. Бу хакта Россия Мәгърифәт министрлыгының Telegram каналында хәбәр ителә.

Быел рус теле, математика һәм җәмгыять белеме – гадәттәгечә, төп дәүләт имтиханының иң популяр фәннәре. Аларны тугызынчы сыйныфта укучыларның күпчелеге тапшыра. Шуңа күрә мондый имтиханнарга укытучылар һәм башка белгечләр күбрәк санда җәлеп ителәчәк. Шуны истә тотып, министрлык бу фәннәрдән имтихан тапшыру көннәрен бердән икегә озайткан. Чит телләр буенча БДИ тапшыруда да үзгәрешләр бар. Әйтик, инглиз, немец, француз һәм испан теле буенча имтиханның 39 нчы биремен кәгазьдә түгел, ә электрон рәвештә эшләргә кирәк булачак. Моннан тыш билге куюга карата да кайбер таләпләр үзгәртелгән.

Киңәш

Бармы борчуга дәва?

Соңгы арада кешенең психологик халәте турында күбрәк сөйли башладык. Эчтән борчу, курку хисләре ашаганда, тынычлыкны ничек саклап калырга соң? Киңәш сорап, кабат психолог Галия ГЫЙМАДИЕВАга мөрәҗәгать иттек.



pixabay.com

1. Мәгълүмат күплек нәрсәсе белән зыянлы?
Буш контейнерны күз алдыгызга китерегез. Без аны көн саен төрле тәм-том белән тутырабыз, ди. Бер айдан соң бу контейнерның эчлеге белән ни булыр? Аннан начар ис килә башлаячак, бу ризыкларны ашарга да мөмкин булмаячак. Ә хәзер шул контейнерга инде бозылган азык-төлек, сасы ис килеп торган нәрсәләр салабыз дип күзаллыйк. Чүп-чар, кыскасы. Контейнер эчлеге инде башлангыч этапта ук сасый башлаячак. Баш миебез белән дә шул ук хәл. Теләсә кайсы хәбәрне, яңалыкны, мәгълүматны «йота» башласак, организмга зыян киләчәк. Бу борчылуга китерәчәк, кәеф төшәчәк, төшенкелек халәте биләп алачак. Артык күп мәгълүмат камалышында калсаң, нишләргә? Иң элек үзеңә «Бу миңа кирәкме? Бу минем өчен шулкадәр мөһимме? Шушы кадәр мәгълүмат белән мин алга таба нәрсә эшләрмен?» дигән сорауны бирергә. Кыскасы, үзеңә кирәклесен генә сайлап алырга кирәк.

2. Бер-береңне аңламау, фикер бәрелешләре, төшенкелек... Бу кадәр тискәре хисләрдән ничек акылдан шашмаска?
Кешенең теге яисә бу вакыйгага карата бик гади биологик реакциясе бар. Ул кыргый хайваннар дөньясында да күзәтелә. Бу – «Сук, йөгер, үрә кат» кагыйдәсе. Ягъни кеше йә һөҗүм итә, йә куркыныч саналган урыннан кача, күчеп китә (әйтик, кешеләр белән аралашмый, эштән китә), йә берни булмагандай яшәвен дәвам иттерә. Киеренке вазгыятьтә бу реакцияләр табигый. Ул – кешенең үз борчуы, эч пошуы белән көрәшү, үзен куркынычтан саклау ысулы.

Һәр кешенең – үз фикере һәм һәр кешенең аны белдерергә хокукы бар. Мөнәсәбәтләрне бозмас өчен, якын кешеләр белән аралашканда, шуны истә тотарга һәм килешеп куярга кирәк: сәясәттән, хәзерге вазгыятьтән кала бар нәрсә хакында да сөйләшәбез! Юкса бу һәр якны да кабат ярсуга, төшенкелеккә китерәчәк.

3. Социаль челтәрләрдә үзеңне ничек тотарга?
Социаль челтәрдәге сәхифәгез ул – сезнең шәхси мәйданчыгыгыз. Сәхифәгездә ил-көн вакыйгалары турында фикер алышмасыннар дисәгез, бу хакта алдан ук белдерергә кирәк. Кемдер бу кагыйдәгә буйсынмый икән, кисәтү ясарга мөмкин. Социаль челтәрләрдә блокка кую да мөмкин.

4. Үзеңне ничек кайгыртырга?
Борчу хисләрен кичерү табигый. Шуңа күрә үзегезгә карата мәрхәмәтле булыгыз. Бу – ни дигән сүз? Үзегезне кичергән хисләрегез өчен тәнкыйтьләмәгез, башкаларга сүзләтә һөҗүм итмәгез, дискомфорт тудырган мәгълүмат каналларыннан, мәйданчыклардан баш тартыгыз.

Сүзгә-сүз

tass.ru

Михаил МУРАШКО, Россия сәламәтлек саклау министры:

Үлем-китем күрсәткече алдагы еллардагыдан кимрәк. Аерым алганда, 2021 елда онкология авыруларыннан интегүчеләр арасында бу күрсәткеч 5 процентка диярлек кимеде. Әлеге чирне вакытында ачыклау халык өчен дә, медицина хезмәткәрләре өчен дә мөһим.

(«ТАСС»)

РОССИЯДӘ – КИТАП УКУ

«ЛитРес» хезмәте Россиядә яшәүчеләрнең әдәбиятка булган кызыксынуын тикшергән. Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, ил халкы икътисадка бәйле китапларны күбрәк укый башлаган. Боевик, хоррор юнәлешендәге китапларга кызыксыну кимегән.

НИНДИ КИТАПЛАРГА КЫЗЫКСЫНУ АРТКАН?

Икътисади китаплар	56%
Мәхәббәт турында романнар	46%
Фантастика	20%
Классик әдәбият	9%
Политология китаплары	9%

Төзекләндерүгә акча бар

Быел Татарстанда 15 сырхауханә төзекләндереләчәк. Төзекләндерү эшләренә 247 миллион сум чамасы бүлеп бирелгән. Дәүләт сатып алулары сайтында бу җәһәттән тендер урнаштырылган. Анда катнашуга заявканы 16–24 мартта тапшырырга мөмкин. Капиталь төзекләндерүне 30 ноябрьгә тәгәлләү зарури.

Төзекләндерелергә тиешле дәвалау оешмалары исемлегенә Аксубай, Алексеевск, Югары Ослан, Зәй, Яшел Үзән, Кайбыч, Кукмара, Лениногорск, Мамадыш һәм Теләче районнары сырхауханәләре кергән. Моннан тыш Зәй һәм Кайбыч районнарының хатын-кызлар консультациясе биналарына, Теләче районында балалар сырхауханәсенә ремонт ясалачак.

Ике бәйрәмгә – җиде көн ял

Май елның ялларга иң бай айларыннан берсе булып тора. Күпләребез аны, ял итүдән бигрәк, бакчада иркенләп эшләү өчен көтеп ала.

Май ае 31 календарь көненнән тора. Быел шуның 18е – эш, 13е – ял һәм бәйрәм көннәре. Гадәттәге яллардан тыш, 1 Май – Яз һәм Хезмәт бәйрәме, 9 май – Җиңү көне өчен өстәмә яллар бирелә. Производство календаре буенча, ай башында тоташ өч көн: 1–3 майда ял итәбез. Ә инде Җиңү бәйрәмендә дүрт көн ял: 7–10 майда ял итү күздә тотыла.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЗУР СУГЫШКА ӘЗЕРЛӘНЕРГӘМЕ?

Дөнья вакыйгалары Украина конфликты тирәсендә бөтерелүләрен дәвам итә. Россияне блокадага алу планнары тулысынча ук барып чыкмый. Бердән, дөнья илләре, аеруча Көнбатыш, углеводородларга мохтаҗлык кичерә һәм санкцияләр астында калган илдән газ һәм нефть сатып алуны дәвам иттерә. Әмма киләчәктә Себердән килә торган энергия чыганакларыннан баш тарту стратегиясе сайланды һәм шул юнәлештә кызу рәвештә эш дәвам итә. Көнчыгыштан килгән газ агымнарына аеруча бәйле булган Германиянең вице-канцлеры Роберт Хабек үткән атнада Дохада булды һәм Катар газын сатып алу турында сөйләшүләр алып барды. Катар әмире белән очрашканнан соң, ул озак сроклы энергетик партнерлык турында килешү төзелүен хәбәр итте һәм бу карарның көчле импульс бирүен әйтте.

Вашингтон Россиягә аркадашлык итүдән баш тартмаган Пекинга басым ясарга тырыша. Үткән җомгада Байден белән Си Цзиньпин видеоконференция форматында ике сәгатьлек сөйләшү уздырдылар. Соңыннан Кытай ягы үзенең тынычлык тарафдары булуын, әмма үз карарларында бәйсез калуын белдерде. Пекин килеп туган вазгыятьтә НАТОны гаепли. Океан артындагылар Әнкара белән дә актив консультацияләр алып баралар. Россиянең рәсми мәгълүмат чаралары, АКШ Төркияне Россиядән сатып алган С-400 зенит-ракета комплексларын Украинага бирергә өнди, дип әйтәләр. Алмашка океан артыннан Әнкарага F-35 хәрби очкычлары вәгъдә итәләр. Бишенче буын хәрби самолетларга караган бу очкычларны Төркиягә сатуны тыйганнар иде. Акчасын алдан түләп куюга карамастан, Әнкара бер истребитель дә ала алмады. Хәзер С-400не Украинага бирсә, Төркия хәрби өлкәдә Америка санкцияләреннән котылачак. Әнкараның позициясе мәгълүм түгел. Конфликтка кергән илләрнең икесе белән дә яхшы мөнәсәбәт сакларга тырышучы Әрдоган Вашингтон басымына буйсынса, Россия белән Төркия арасында киеренкелек пәйда булачак, билгеле. Мәскәү Әнкараның Киевка «Байрактар»лар сатуына сабыр итсә дә, украиннарның Россиянең үз коралы белән үзен тукмавына риза булмаячак, әлбәттә.

Бик күп мәнфәгатьләр кисешкән урында нәрсәнең шартлап өзеләсен, кайсы җепләрнең үзара бәйләнәсен әйтү кыен. Йәмән гыйсъянчылары, Согуд Гарәбстанының нефть инфраструктурасын җимерү өчен, беспилотниклар куллана башлады дигән хәбәр килде дүшәмбе иртәсендә бу юллар авторына. Корольлек әллә ничә елдан бирле инде гыйсъянчыларга каршы махсус хәрби операция алып бара, нәтиҗәләре генә еларлык. АКШтан алган югары технологияле коралларга ия булу да булышмый.

Үткән атнада Франция Президенты Макрон: «Безнең континентта башланырга мөмкин булган югары интенсивлыктагы хәрби конфликтка әзер булу өчен, безгә инвестицияләрне арттырырга кирәк», – дип белдерү ясады. Сүзнең Россия белән бәрелешү хакында баруын аңлау кыен түгел. Польша Президенты Анджей Дуда оборона турындагы законга имза салды. Поляк армиясен ике тапкыр арттырып, 300 мең солдатка җиткерү планлаштырыла. Төньяк Атлантик блок белән Россия конфликты ихтималлыгын бу юлларның авторы иллегә – илле дип бәяли. Куркыныч көннән-көн үсә һәм хәтта Киев белән Мәскәү тыныч килешүгә ирешсәләр дә, зур сугыш ихтималы калачак.

Россиядә

ТИЗ ГЕНӘ ТУКТАТЫП БУЛМАС

Махсус хәрби операция Россиянең эчке тормышында да зур сикәлтә китереп чыгарды. Икътисад паровозы зур тизлектә тупикка таба хәрәкәт итә һәм тормозларга басып, аны башка рельсларга күчерү өчен гадәттән тыш тырышлык куярга туры килә. Икътисад театрының төп режиссеры – Үзәк банк үткән җомгада яңадан утырышка җыелды. Төп ставка 20 процент килеш кала. Аны күтәрүнең дә, төшерүнең дә бик әһәмияте юк бугай инде, чөнки инфляция барыбер ярлардан ташый. Чит ил товарларына гадәттән тыш бәйлелек үз сүзен әйтә. Россия автозапчастьларның – 95 процентын, уенчыкларның – 92, аяк киеменең – 87, өс киемнәренең 82 процентын тышкы базарлардан ала икән. Соңгы өч позицияне үз товарларыбыз белән алыштыру артык кыен булмас булуын. Хәзер хосусый бизнес бар, ул тиз хәрәкәт итүчән. Әмма, әйтик, кием тегәм дисәң дә, тукыма кирәк. Текстильгә чит илләрдән бәйлелек – 73 процент. Тегү машиналары табу, кадрлар әзерләү дә бер-ике көнлек кенә эш түгел. Телеком җиһазларга 86 процент бәйлелектән ничек котыласы? Монысы – зуррак проблема, чөнки югары технологияләр таләп итә, зур җитештерү мәйданнары сорый. Үзәк банкта да килешәләр моның белән. Элек үзебездә җитештерү рентабельле булмаган товарларны эшләп чыгару хәзер табышлыга әйләнәчәк, әлбәттә, әмма вакыт сорый, диләр. Шул сәбәпле инфляциянең түшәмгә сикерүен ике елсыз да туктатып булмас, дип саный Нәбиуллина ханым.

Үзәк банк та, башка рәсми чыганаклар да үзебездә җитештерелгән товарларның бәясе күккә чөелүенә борчыла. «Сатып алу «бизгәге» шикәрдән кер юу порошокларына һәм гигиена чараларына сикерде», – дип билгеләп үтә «Российская газета». Офис кәгазенә бәяләр биш-сигез тапкыр сикерде. Дефициткa да әйләнеп бара әле ул җитмәсә. Урманнар – безнеке, кәгазь – чит илдән шул, берни дә эшләп булмый. Бәяләрнең төп генераторы – әлегә товарга кытлык түгел, ажиотаж, әлбәттә. Кешеләр акчага ышанмыйлар, кулдагы чыпчыкны һавадагы торнадан яхшырак дип санאיйлар. Шул сәбәпле рәсми хакимиятләрнең тынычландырырга тырышуы кире нәтиҗә генә бирә. ВТБ банкы физик затларга да алтын коелманы сумнарга сата башлаган икән. Тотрыклы алтын бәясе урнаштырып булса, сумга ышаныч артыр иде, әмма алтын сатып алуның минималь күләме – бер кило. Киң массаларның кысыр акча янчыкларына бер кило алтынлык акча каян килсен ди инде. Бик тырышсаң, бер-ике унциягә акча табып булыр, бәлки. Шуңа күрә алтын сәүдәсе дә киң таралыш ала алмаячак һәм финанс тотрыклылыгына китермәячәк. Әлегә шунысы куандыра: сум курсы бераз күтәрелде. Долларны безгә сатмыйлар инде сатуын, бәлки, импорт товарлар бәясе тотрыкланыр. Валюта булганда да, сәүдә итү кыен әле монда. Кытай бизнесы, әйтик, безнең белән товар алышырга бик риза, әмма чин банклары, АКШ таләбенә буйсынып, акча күчерергә бик ашыкмыйлар. Шул сәбәпле юаньдагы резервларны да бик файдаланып булмый икән әле.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

БЕРГӘ БАРЫБЕР ҖИҢЕЛРӘК

tatarstan.ru

Саклап калу өчен, бергәләп эшләргә. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, эшмәкәрләр белән очрашып, хәзерге шартларда эшләү мөмкинлекләре хакында сөйләште.

Президент әйтүенчә, Көнбатыш илләре Россиягә карата моңа кадәр күрелмәгән икътисади басым ясый. Дәүләт җитәкчесе тарафыннан халыкка һәм җәмгыятьнең төрле тармакларына ярдәм итү буенча чаралар күрелә. Республика дәрәҗәсендә дә икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча ниләр эшләү билгеле.

Татарстан Президенты бизнес белән хакимияткә бергәләп атларга кирәк дигән фикердә. Ягъни килеп туган проблемаларны уртага салып хәл итәргә.

– Безгә сезне ишетү мөһим. Банклар белән эш, логистика хезмәте – сораулар күп, барысына да безнең катнашуыбыз кирәк. Без сезнең белән, – диде Рөстәм Миңнеханов эшмәкәрләргә.

Бизнес вәкилләре үзләрен ишеттерергә тырышты да. Әйтик, «Кориб» компанияләр төркеме генераль директоры Олег Коробченко, күзәтчелек органнарына планлы тикшерүләр үткәрми торырга кушылса да, планнан тыш тикшерүләр турында гаризалар килүдән зарланды. Чикләүләр белән күзгә-күз очрашкан эшкуарларга бу – өстәмә авырлык.

Рөстәм Миңнеханов исә тикшерүләрдән тулаем баш тартып булмавын әйтте. Әмма эшкуарларны да кыен хәлдә калдырырга ярамый.

– Тикшерүләр кирәк ул, тик хәзер ике яманның берсен сайлыйсы гына кала. Сәнәгатьнең эштән туктамавы мөһим. Бәлки, бу җәһәттән «кайнар элемтә» булдырырга, мәгълүмат базасы оештырыргадыр, – дип тәкъдим итте республика җитәкчесе.

«Ирэн» остаханәсе генераль директоры Ирина Купряхина мәктәп формасы тегү өчен тукымалар сатып алу белән мәшәкатьләр барлыгын әйтте. Президент сүзләренчә, хәзер үзебездә җитештерүне көйләп җибәрергә вакыт. Аның сүзләренчә, Төркия, Кытай, Үзбәкстан белән логистиканы җайларга кирәк.

Башка эшкуарлар кредит каникуллары, электрон сату мәйданчыкларына чыгу юллары, төзелеш материаллары, ярдәм чараларыннан файдалану таләпләре турында сорашты.

Президент очрашу азагында бизнес вәкилләрен берләшергә чакырды.

– Без бүтән базарларга игътибар итәргә, шулай ук үз-үзебезгә күбрәк ышанырга, үз-үзебезне тәэмин итәргә тиеш. Ничек кенә авыр булмасын, бу юлны узарга кирәк. Эшлекле мөнәсәбәтләрне югалтмаган партнерлар белән эшләү ягын карыйк. Ә алар күп, – диде Рөстәм Миңнеханов.

* * *

Тышкы кыяфәтен бозмаска, мәдәни мирас объектларына зыян китермәскә тиеш. Хөкүмәт йортында тарихи җирлекләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге буенча ведомствоара комиссия утырышы узды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кайбер төзелеш проектлары белән танышты.

Республиканың тарихи җирлекләрендә: Казанда – 6 һәм Свияжскида, Лаешта берәр объект төзү күздә тотыла.

Утырышта иң элек Казанның Париж Коммунасы урамындагы тулай торак бинасы, 25 октябрь урамындагы, Бутлеров урамындагы күпфатирлы торак йортлар проектлары каралды. Шулай ук «Спартак» аяк киеме фабрикасы биналарын яңарту концепциясе белән таныштылар. Моннан тыш Тукай урамында тулай торак бинасы белән бергә Мөхәммәдия мәдрәсәсенең административ бинасын төзү проекты буенча фикер алышу булды. Ул Болгарда ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан төзеләчәк.

Комиссия әгъзалары Свияжскида иконалар ясау остаханәсе проекты буенча да фикер алышты. Проектларның барысы да хупланды.

Лаешның «Ак мәчет» төзелеше проекты кабат карап тикшерүгә чыгарылган иде. Объект белән архитектор Андрей Котельников таныштырды. Әлеге проект та хуплау тапты.

* * *

Казан Кремленең Спас манарасы яңартылачак. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашындагы күчмә киңәшмәдә манарага кагылышлы проект-тикшеренү эшләрен хәл итү турында сөйләштеләр.

Спас манарасын XVI гасырда Псков архитекторлары Иван Ширяев һәм Постник Яковлев төзегән. Тарихтан күренгәнчә, ул берничә тапкыр үзгәртелгән.

Манара һәрвакыт ныгытманың капкасы буларак хезмәт иткән. XVI гасырда, күзәтү каланчасы белән, ике катлы куб рәвешендә булган. Советлар чорында анда эш бүлмәләре урнаштырылган. 2017–2018 елларда бүлмәләр чистартылган, диварлары сүтелгән.

Киңәшмәдә «Татинвестгражданпроект» генераль директоры Гадел Хөснетдинов федераль әһәмияткә ия булган мәдәни мирас объектында проект эшләренең барышы белән таныштырды.

Татарстан Президенты Спас манарасы бүлмәләрен карады, техник-икътисади күрсәткечләре, интерьеры белән кызыксынды.

Рөстәм Миңнеханов шулай ук манараның бүгенге хәле, проект-тикшеренү эшләре белән танышты. Ул Мәдәният министрлыгына манара эчендәге биналардан алга таба файдалану концепциясен эшләүне йөкләде.

Бәйрәм уңаеннан

Дәвамчылар үсеп килә

Татарстанда агач кәлшәләре җитәрлек күләмдә. Шуңа илдәге вазгыять урманчыларны куркытмый. Техниканың 95 проценты үзебездә җитештерелә, шулай да чит илдән кертелгән кайбер агач кисү техникаларына запас частьлар табу кыенлашырга мөмкин.

Урманчылар моның да җаен тапкан. Кирәк-яракны алдан алып куйган. Казан дәүләт авыл хуҗалыгы университетында узган «Халыкара урманчылар көне»нә багышланган очрашуда Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров шулай диде. Аның сүзләренчә, алдагы елларда да борчылыр сәбәпләр булмаячак.

– Республика урманчылыкларында эшләп килүче 51 питомникта бөтен республикага җитәрлек кәлшә үстерәбез. Чит илдән орлык керткәнебез юк. Барысы да үзебезнеке. Запасыбыз да җитәрлек. 2012 елдан бирле Саба орлыкчылык-селекция үзәгендә ел саен 12 миллион төп кәлшә җитештерелә. Мондагы кәлшәләр нык була. Бер ел эчендә аларның озынлыгы 35 сантиметрга җитә. Ә гади питомникта үстерелгәннәренә әлеге биеклеккә җитү өчен 3 ел кирәк, – диде министр.

Равил Кузюров урман янгыннарына да тукталды. Узган елгы эсселек урманны да читләтеп үтмәде. Министр әйтүенчә, алар янгынга әзер.

– Апрель башыннан урманнарны янгыннан саклау башлана. Безнең янгынга каршы тору өчен бөтен кирәк-ярак бар. Әмма шунысын да онытмыйк: урман үзеннән-үзе янмый. Күп очракта кеше гаепле. Шуңа да без гел очрашуда, сөйләшүдә. Инспекторларыбыз халыкны кисәтеп чыкты. Урман янәшәсендә яшәүчеләр белән аерым очрашулар булды. Без үз ягыбыздан әзер. Халыкны да уяу булырга чакырабыз. Тирә-якны, урманнарны бергәләп сакласак иде, – ди ул.

Урманчыларның эше янгын хакында кисәтү белән генә бетми әле. Агачлардагы авыруларны да алар күзәтеп тора. Кирәк икән, чирне бетерү чарасын күрә башлыйлар. Равил Кузюров Татарстан урманнарында әллә ни куркыныч авыруларның юклыгын әйтте.

– Агачлардагы авырулар карлар эреп беткәч күренә башлый. Һәр чиргә үз дәвасы булган кебек, агачларга да махсус дарулар бар. Без аларны кисәтү максатыннан сибеп чыгабыз. Шөкер, соңгы елларда агачлар авырмый. Берничә ел элек Башкортстан ягыннан ефәк чире кергән иде. Бу авыру Азнакай, Менделеевск якларында күзәтелде, – ди ул. – Ылыслы агачларда «тамыр губкасы» чире дә күзәтелгәли. Әмма соңгы елда бу чир белән дә очрашканыбыз юк.

Равил Кузюров урманчыларның хезмәт хаклары ике мәртәбә күтәрелеп, уртача 32 мең сум тәшкил итүен дә әйтте. Эшкә килүче яшьләр дә җитәрлек. Инде бүген үк урман хуҗалыгында эшлим дип торучы егет-кызлар бар. Әйтик, Казан дәүләт авыл хуҗалыгы университеты студенты Ксения Мостякова төрле үсентеләр үстерә. Үз эшен министрга да күрсәтте. Ул кайда эшлисен белә инде – киләчәген урман белән бәйләячәк.

– Урманга эшкә килүче яшь белгечләргә дәүләт ярдәм итә. Көллият тәмамлаучыларга –150 мең, университеттан килүчеләргә бер тапкыр 300 мең сум акча бирелә. Кадрлар кытлыгы бар дия алмыйм. Кайда да шулайдыр инде, берәү килә, икенчесе китә. Әмма шулай да урманда бары тик үз эшен яраткан кеше генә эшли дип әйтә алам, – ди ул.

Урманның киләчәге – яшьләр кулында. Арча районындагы «Табигать варислары» дип аталган мәктәп урманчылыгы мөгаллимәсе Эльмира Лотфуллина шулай ди. Хәзерге көндә Арчада 59 бала урман хуҗалыгы белән кызыксына.

– Әлеге балалар табигать сагында тора. Өмәләргә дә чыга, агач та утырталар, орлыклар да җыялар. Озаклямый Кошлар көне булачак. Анда да катнашалар. Сыерчык оялары да ясый башладылар инде, – ди Эльмира ханым. – Араларында республика, Россия күләмендә уздырылган бәйгеләрдә, олимпиадаларда җиңүчеләр дә бар. Борчылыр урын юк – дәвамчылар үсеп килә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

tatarstan.ru

ТӨП ИГЪТИБАР – АЗЫК-ТӨЛЕККӘ

Көн кадагында

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә ассызыклаганча, хәзерге шартларда халыкны төп азык-төлек продуктлары белән тәэмин итәргә кирәк.

– Без сүздә генә түгел, гамәлдә дә азык-төлек товарлары белән тәэмин итү мәсьәләсендә борчылырга сәбәп юклыгын күрсәтергә тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Агросәнәгать комплексы базарның ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм башка төбәкләргә ресурслар бүлеп бирү өчен җитәрлек мөмкинлекләргә ия.

Республика шәһәрләрендә авыл хуҗалыгы ярминкәләре атна саен үткәреләчәк.

– Башка шәһәрләрдә дә ярминкәләр лаеклы узуга игътибар итәргә кирәк, – дип белдерде Президент. – Без моның ни дәрәҗәдә кирәк һәм мөһим икәнен аңлыйбыз. Мондый авыл хуҗалыгы ярминкәләре тотрыкландыру ролен башкара. Анда кирәкле барлык продукция сатылырга тиеш.

Киңәшмәдә Татарстан Премьер-министры урынбасары – Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров та чыгыш ясады. Ул язгы кыр эшләренә әзерлек, авыл хуҗалыгы техникасы, орлыклар һәм ашламалар базарындагы агымдагы вазгыять турында сөйләде. Министр китергән мәгълүматлар буенча, республикада чәчү мәйданнарын 2021 ел дәрәҗәсендә саклап калу планлаштырыла. Бу – 2,72 млн гектар дигән сүз. Марат Җәббаров былтырдан калган терлек азыгы запасы булмау сәбәпле, бөртекле культуралар исәбенә терлек азыгы җирләре арттырылачагын да хәбәр итте. Шунысы куанычлы: бөртекле, кузаклы һәм ярма культуралары орлыклары белән тәэмин ителеш 115 процентны тәшкил итә, проблемалар булмаячак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Дөрес, сатып алынган орлыкларны кайтару буенча авырлыклар бар, тик алар хәл ителәчәк, дип ышандырды Марат Җәббаров. Март ахырына кадәр килешенгән 62,5 мең тонна шикәр чөгендере, 67,5 мең тонна көнбагыш, 4,5 мең тонна кукуруз кайтарылырга тиеш.

– Орлыкка бәяләрнең сизелерлек артуы күзәтелә, чөнки алар чит ил валютасында (доллар, евро) контрактланган. Аларны алмаштырырга да мөмкин. Базарда үзебезнең селекция сортлары һәм гибридлары җитәрлек, – диде министр.

Аның сүзләренә караганда, республикада 478,8 мең гектар уҗым культуралары бар. Алар кышны яхшы чыккан. Шулай ук язгы кыр эшләренә төп техника да әзер. Әмма кайбер кыенлыклар бар. Запас частьларга бәяләрне – 50, авыл хуҗалыгы техникасына бәяләрне 30 проценттан 50 процентка кадәр арттырганнар. Кыр эшләре өзелмәсен өчен штаб эшли, анда үсемлекләрне саклау чараларын, минераль ашламалар, орлыклар, запас частьлар китерүне көндәлек режимда күзәтеп торалар, кирәк булганда альтернатив хәл итү юллары карала. Азык һәм урып-җыю техникасын әзерләү дә зур борчу тудыра. Бүгенгә кирәкле запас частьларның нибары 24 проценты сатып алынган.

Катлаулы чорга карамастан, ел башыннан хуҗалыклар тарафыннан 689 техника (2,4 млрд сумнан артык) сатып алынган. Техника белән проблемалары булган хуҗалыкларга механикалаштырылган отрядларны җәлеп итәргә киңәш ителде. Президент Рөстәм Миңнеханов орлыклар белән тәэмин итү өлкәсендәге ситуацияне, шулай ук республика кырларында язгы кыр эшләрен уздыру өчен кирәкле барлык шартларны тикшереп торырга кушты.

Халыкны азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсе Икътисад министрлыгының да игътибар үзәгендә. Татарстан Премьер-министры урынбасары – икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов киңәшмәдә хәбәр иткәнчә, узган атнада халыкта озак саклана торган продуктларга ихтыяҗ арткан. Шул ук вакытта, аннан алдагы атна белән чагыштырганда, сату күләме кимегән, әмма әле һаман да уртача куллану күләменнән югарырак. Халыкны азык-төлек белән тәэмин итү өчен ваклап сату сәүдә челтәрләренә кайбер товарлар китерү артты, дип билгеләп үтте министр.

Мидхәт Шаһиәхмәтов киштәләрдә товарларның булуын, бәяләр артуын контрольдә тотар өчен Федераль антимонополия хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе эшләвен дә искә төшерде. Ул шулай ук якын арада халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү – җәмәгать эшләре, эштән азат ителү куркынычы янаган хезмәткәрләрнең вакытлыча эш белән тәэмин ителеше; сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләрен профессиональ укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча Россия Хөкүмәте карарлары кабул ителәчәген хәбәр итте. Моннан тыш, Мидхәт Шаһиәхмәтов әйтүенчә, агросәнәгать комплексына, сәнәгать һәм сәүдә оешмалары өчен ташламалы кредитлар биреләчәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

МАНСУР БАТЫР

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

«Без булмасак, кем?» Бу сүзләрне һәрберебезнең мең тапкыр ишеткәнебез, укыганыбыз бар. Һава десанты гаскәрләрендә (ВДВ) хезмәт иткән егетләрнең девизы шундый. Иң авыр гаскәри бурычларны дәүләтебез иң беренче шул егетләргә тапшыра. Чөнки бу Россия хәрби көчләренең «каймагы» – элитасы.

Менә шул асыл егетләрнең берсе – Батыров Мансур Нурулла улын Мамадыш районында белмәгән кеше бик сирәктер. Районда гына да түгел, республикабызда, илебез киңлекләрендә, дип әйтсәм дә ялгыш булмас, чөнки аның шифалы, җанга җылы вәгазь-догаларының файдасын күреп, шифасын алып, Аллаһның рәхмәтләрен укып китүчеләрнең саны бик күп. Мамадыштагы «Изге нур» мәчетенең алыштыргысыз имамы булып хезмәт итә ул. Әйе, чыннан да хезмәт итү, дип атыйм мин Мансур хәзрәтнең Ходай юлыннан барып, кешеләрне дини һәм рухи яктан баетуын, яктылыкка өндәвен.

Алма агачыннан ерак төшми, диләр безнең халыкта. Дөрестән дә шулай икән ул. Егерменче гасыр башында гомер иткән дәү әнисе Дөррикамал (бездә халык якын итеп «Дөррикамалттәй» дип искә ала иде) янына, аның шифасын алырга дип, Шәдче авылына ерак араларны якын итеп килә халык. Хәтта бервакыт Совет киноларының танылган актеры да Мәскәү каласыннан Дөррикамал апа янына ярдәм сорап килгән, дип сөйлиләр иде белгән кешеләр. Дөррикамал апа Мансур атлы яраткан оныгына үзенең бар ягымлылыгын, кулларының шифасын биреп, хәер-догасын калдыра да инде.

Әти-әнисе Нурулла абый белән Мөгәздәмә апа икесе дә колхозда хезмәт куялар. Авылның үрнәк гаиләсе булып, ике ул, бер кыз үстерәләр. Мансур урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Литвада һава десанты гаскәрләрендә хәрби бурычын үтәп, туган авылына әйләнеп кайта. Җырга-моңга гашыйк, оста гармунчы егет читтән торып Алабуга мәдәни-агарту уку йортына укырга керә, авылның мәдәният йортында мөдир булып эшли. Соңрак десантчы егет, үзен тагын кырыс сынауларда сынап карарга дип, Нефтеюганск, Нижневартовск якларына нефть разведкасы оешмасына эшкә кереп, тугыз ел хезмәт куя. Шул елларда авылның иң уңган, акыллы кызларының берсе булган Фәүзия белән тормыш кора. Туксанынчы елларда Мансур Нурулла улы – колхоз рәисе, аннан соң озак вакытлар Шәдче авылы картлар йортында мөдир булып эшләп ала. Үз көчләре белән йорт салып чыгалар. Үрнәк гаилә традицияләрен дәвам итеп, Мансур белән Фәүзия дүрт кыз тәрбияләп үстерәләр.

Дингә тартылу канына сеңгән булган инде. Тормыш юлын кискен үзгәртеп, үзлегеннән «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» мәдрәсәсенә укырга кереп, аны уңышлы тәмамлый. Инде менә 15 елга якын Мансур хәзрәт – Мамадышның «Изге нур» мәчете имам-хатыйбы. Һәр көнне җил-суык дими, буран-кар дими, Шәдче – Мамадыш арасын (35 чакрым ара) йөреп, үз вазыйфасын башкара. Аннан үзенең туган авылы мәхәлләсендә дә имам-хатыйп бит әле ул. Авылдашлары бертавыштан, Мансур хәзрәт, син безне ташлама инде, дигәч, үтенечләрен кире кага алмады. Башкача була алмый – халыкның ышанычы аның өчен буш сүзләр түгел! Туксанынчы елларда җиткерелгән авыл мәчетенең җылылык системасын, тәһарәтханәне яңартуга үзенең һәм иганәчеләрнең тырышлыгы белән берничә йөз мең сумлык эшләр башкардылар узган ел. Иртәнге, кичке намазларны укыта хәзрәт туган авылында. Замана тыныч түгел, дип тормады: ике ел элек һәр мөселман кешесенең изге бурычы, фарыз гамәле булган хаҗ кылып кайту насыйп булды үзенә. Шулай да, һәр елның бер көнендә, 2 августында, түбәтәен салып куеп, кадерләп саклана торган зәңгәр беретын киеп куя да яшь чакларын, хәрби дусларын искә ала ул.

Сәләт – галимнәр аңлатуынча, бик тә күпкырлы һәм бөтенлеккә ия күренеш. Әбисе Дөррикамалдан калган, Ходай биргән сәләтне ул күптәннән сизеп йөри. Яшьрәк чагында да күрше-күлән авырып торучы балаларын Мансурга алып керә торган булган. Сихәтле догаларыннан соң, Ходай рәхмәте, бала-чага изрәп йокыга талып, савыга торган булган. Хәзер инде Мансур хәзрәт, ялварып, ярдәм сорап килгән кешеләрне кабул итеп, өшкереп, үзенең шифасын бирә. Ярдәме дә тия. Рәхмәт укучылар бик күп. Араларында башка дин вәкилләре дә бар.

Мәчет ишекләре һәркем өчен һәрвакыт ачык. «Аллага шөкер, намаз вакытларында мәчетләр халык белән тулып тора, күңел шуңа сөенә, – ди Мансур хәзрәт. – Изге җомга, гает бәйрәмнәребезне әйтмим дә инде. Шунысы куанычлы: яшьләр бик теләп йөри намазларга. Димәк, башкарган эшләребезнең нәтиҗәсе һәм тирән мәгънәсе бар».

Мәчеттә мәктәп балалары өчен якшәмбе дәресләре алып барыла. Якын-тирәдә яшәүче мәктәп укучылары, бик теләп, мәчет ишекләрен ачып керәләр. Анда намаз уку, гарәп телен, грамматикасын өйрәтәләр. Бәйрәмнәрдә балаларны тәм-том, күчтәнәчләр белән сыйлыйлар. Мохтаҗ гаиләләргә ярдәм ел дәвамында алып барыла. Ифтар мәҗлесләрендә тулы өстәл-табыннар белән һәр теләгән кешене каршы алалар.

Бүген Мансур хәзрәт белән тормыш иптәше Фәүзия ханым хөрмәтле әти-әни булу белән беррәттән, яраткан дәү әти белән дәү әни дә. Дүрт кызлары да тормышта үз юлларын табып, шул юл буйлап горур атлап бара, җиде онык үсеп килә, Алла рәхмәте белән. Абыйсы Гомәр, авылга кайтып, туып-үскән нигезләрендә төпләнде. Авылда мәчетне, зиратларны чиста, пөхтә тотуга зур көчен куя. Сеңлесе Роза гомер буе балаларга белем бирде. Мәдрәсәдә дин курсларын бетереп, Ходай кушканча яшиләр – ихтирамлы гаилә.

Нәселләре «Батырлар» булгангадыр инде, Мансур хәзрәт авырлыклардан куркып торучылардан түгел. Башлаган эшен ахырына кадәр һәм җиренә җиткереп башкара. Хәзрәтнең яшәү девизы: «Тырышлык белән, үз халкыңа эчкерсез хезмәт итеп, үзеңнән соң да якты эз калдырырлык итеп яшәргә кирәк бу дөньяда».

Илдар ГАЛӘВЕТДИНОВ

Өлкәннәр тормышы

Кулы эш белгән югалмас

Республика өлкәннәренең бер буш вакыты да юк. Элек, лаеклы ялга чыккач, онык карашсалар, хәзер алар бөтенләй башкача яши башлады. Сызланырга, зарланырга да вакытлары калмады. Берәүләр җыр-моң дөньясына чумды, икенчеләр кул эшләре белән мәш килә. Әнә шуны истә тотып, быел өлкәннәр арасында «Халык иҗаты» дигән бәйге дә узды. Анда 55 яшькә җиткән хатын-кызлар һәм 60 яшьтән өлкән ир-атлар катнашты. Сайлап алу туры февральдә тәмамланды, ә март ахырында җиңүчеләр билгеле булачак. Бәйге «Ветераннар – Татарстан халыкларының мәдәни мирасын һәм үзенчәлеген саклаучылар» дигән проект кысасында тормышка ашырыла.

– Татарстанда дистәләгән милләт вәкиле көн күрә, һәрберсенең бай мәдәни, рухи һәм әхлакый традицияләре, күрсәтерлек эшләре бар. Алар дус-тату яши, үзләренең генә түгел, башка халыкларның гореф-гадәтләрен дә кадерләп саклыйлар, ихтирам итәләр, – ди Татарстан ветераннарының (пенсионерларының) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков. – Узган ел без моңа тагын бер кат инандык. Республикада һөнәрләрне саклау һәм популярлаштыру, һәвәскәр сәнгатьне үстерү эше киңәйде. Ә бит республиканың мәдәни мирасын саклаучылар булып өлкән буын вәкилләре тора, алар халык иҗаты һәм сәнгать һөнәрләре белән шөгыльләнәләр. Аларны башкалар да белсен!

Республиканың барлык район үзәкләрендә һәм шәһәрләрендә халык иҗатын үстерү өчен мәйданчыклар булдырылган. Бу эштә җирле ветераннар оешмаларының роле бәяләп бетергесез. Алар өлкәннәр өчен клублар оештыра, анда ветераннар белән очрашулар, мәктәп укучылары өчен кул эшләре буенча мастер-класслар үткәрәләр. Яшь буынны чигәргә, бәйләргә, агачтан эшләнмәләр ясарга өйрәтәләр. Бу эшләр өлкәннәргә дә уңай тәэсир итә. Алар үзләренең кирәклеген сизәләр. Республика ветераннар советының сугыш ветераннары белән эшләү һәм аларның истәлеген мәңгеләштерү буенча иҗтимагый комиссиясе рәисе Татьяна Сабирҗанова әнә шулай ди.

– 2020 елда коронавирус пандемиясе вакытында бу эшләр онлайнга күчте. Ике ел элек Республика ветераннары советын эшләтеп җибәргән «Ветераннар иҗаты» дигән яңа онлайн проект бик кирәкле булды: өлкән кешеләр WhatsApp төркемендә аралашырга өйрәнде, анда алар кул эшләре, рәсем сәнгате, бакчачылык өлкәсендәге уңышлары белән бүлеште. Кыска гына вакыт дәвамында бу төркемдә кул эшләнмәләренең меңнән артык фотосурәте урнаштырылган иде, – ди ул. – Хәзер без Татарстанның Икътисад министрлыгының «Республика маркетинг үзәге» электрон сәүдә мәйданчыгында ветераннар эшләгән халык иҗаты товарларын сату турында, аларны потенциаль сатып алучылар белән алга таба хезмәттәшлек итү өчен бушлай урнаштыру мәсьәләсен карыйбыз.

Тиздән җиңүчеләр билгеле булачак. Бик теләсәк тә, аларның барысын да җиңүче итеп булмый, ди оештыручылар. Һәр район үз кул эше остасын мактый. Арча районының ветераннар советы рәисе Рәмзия Хәмидуллина да осталар турында горурланып сөйли.

– Безнең якларда кул эше осталары бик күп. Алар арасында чын-чынлап үзенчәлеклеләре бар, – ди ул. – Мәсәлән, Урта Пошалым авылыннан 80 яшьлек Мәймүнә Мотаһарова – чигү, Арчадан 65 яшьлек Зәбидә Шакирова исә – бәйләү остасы, Чума-Елга авылыннан 65 яшьлек Халидә Әхмәдиева – намаз келәмнәре ясаучы, Арчадан Евгений Ефремов, Юрий Демьянов, Евгений Васильев – рәсем осталары. Әлеге проект кысасында район үзәгеннән 59 яшьлек Фәридә Кәримуллина һәм 75 яшьлек Мөнирә Акбашева «Казан арты» этнография музее базасында җирле ветераннар өчен мастер-класслар үткәрделәр.

– Безнең районда хезмәт сөючән, талантлы ветераннар яши, аралашуны чикләү шартларында да алар үзләре өчен кызыклы эш таба беләләр, – ди Апас ветераннар советы рәисе Гөлнур Насыйбуллина.

– Район үзәгендә һәм авыл җирлекләрендә мәдәният йортлары, китапханәләр каршында өлкән яшьтәге кешеләрнең иҗат төркемнәре эшли. Ветераннар мәктәп укучыларына йон эрләп күрсәтеләр, оекбаш, кофта бәйләргә өйрәтеләр. Халык иҗаты конкурсында катнашучылар арасында Каратун станциясеннән 64 яшьлек Гөлбану Фәизова да бар. Ул картоннан декоратив сандыклар, энҗе-мәрҗән эшләнмәләре, курчаклар ясый, – ди ул.

Тиздән нәтиҗәләр билгеле булачак. Оештыручылар өлкәннәрнең осталыгын башкалар күрсен, яшь буын, аларга карап, эшкә өйрәнсен иде дигән теләк белдерә. Башкача мөмкин дә түгел – кулы эш белгән кеше беркайчан да югалмый.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә кандидатлар

ХАЛКЫБЫЗ ХӘТЕРЕНДӘГЕ ХАТИРӘЛӘР

«Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә композитор Фәрит Яруллинга (1914–1943) багышлап, роман-хроника нәшер ителү мәгълүм. Аның авторы – журналист, язучы Рашат Низами.



Әсәрдә моң иясенең тормыш һәм иҗат юлы шактый калку яктыртыла. Иҗатчы аның эзеннән сугыш кырына барып чыга, һәлак булган урынын ачыклау өчен зур тырышлык куя. Композиторның Киев шәһәрендә яшәгән бердәнбер кызы Наиләне табып, гаилә хәтерендә сакланган хатирәләрне халкыбыз хәзинәсенә әйләндерә.

Эзтабар язучы, гомумиләштерү ясап, төп сорауга җавап эзли. Ягъни дөнья алкышлаган «Шүрәле» балетын язып калдырган Фәрит Яруллинның ни өчен сугышка җибәрелүе белән кызыксына. Йөз елга бер туган кабатланмас сәнгать әһеленең тылда калдырылмавының сәбәпләрен ачыкларга тели. Композиторлар берлеге рәисе Нәҗип Җиһанов, үзеннән дә сәләтлерәк хезмәттәшен фронттан аралау өчен, нигә югары даирәдә хәлиткеч сүзен әйтми? Битарафлыкмы бу? Әллә көндәшне нәтиҗәле иҗаттан ерагайтуның бер мәкерле алымымы?

Җанга тынгылык бирмәүче әлеге сораулар, кулга Рашат Низаминең «Татар моңының өч йолдызы» китабы килеп кергәч, менә тагын баш калкыта. Алай гына да түгел, монда автор Фәрит Яруллин язмышын кайгыртудан тыш, Салих Сәйдәшевче, Рөстәм Яхинчы буларак та таныла.

Югыйсә Салих Сәйдәшев (1900–1954) иҗатын өйрәнүгә Салих Шамовның байтак гомерен багышлавы билгеле. Ул күренекле замандашын тарихта калдыру өчен гомеренең соңгы көннәренә кадәр җан талаша. Төрле концерт-тамашаларда китабын таратырга омтыла. Эзләнүчән Рашат Низами да «Сәйдәшнең соңгы елы» дигән роман-кыйсса яза. Яңа китабын шушы әсәре белән башлап җибәрә.

Язучы искәрткәнчә, әтисе Җамалетдин салкын тидереп, дөньядан вакытсыз китсә дә, ятим Салих Казандагы җизнәләре Насретдин белән Шиһап Әхмәровтан уңа. Әнисе Мәхүпҗамал белән аларның өйләренә сыена. Зыялы мохиткә эләгеп, артист Габдулла Кариев, шагыйрь Габдулла Тукай, музыкант Заһидулла Яруллин һәм башка күренекле шәхесләр белән очраша. Аларның теләктәшлеген тоеп, моң дәрьясына якыная. 1 нче Татар укчы бригадасында трубачы һәм капельмейстер була, репертуар сайлый, җыр һәм нота дәресләре бирә. Казанда Татар дәүләт театры оешкач, 22 яшьтә музыка бүлеге мөдире, дирижёр итеп чакырыла. Драматург, актёр, режиссёр Кәрим Тинчурин белән бергәләп, каторжан кебек эшләп, музыкаль драма жанрын терәкләндерә. 1929 елда киләчәктә Бөек Ватан сугышының төрле фронтларында, Кызыл мәйданда яңгыраячак, СССР Оборона халык комиссары маршал Климент Ворошиловның исемле сәгатенә лаек булачак Кызыл Армия маршын яза… Тик шулай да, иҗаты шаулап чәчәк атса да, композитор күңеленә үзләре җырлап килгән көйләрне күпсенүчеләр табыла. Язганына «мәгарә җыры» дигән тискәре бәя бирүчеләр күренә. Эштә кыскартуга да эләгә, сәхнәдә кечкенә рольләр башкара. Дусты һәм фикердәше Кәрим Тинчурин «халык дошманы» дип кулга алынгач, ул кемгә таянырга да белми. Дөньяның асты өскә килгәндәй була, тирә-юньне шом һәм әләк баса. Тинчурин пьесалары сәхнәдән алынгач, Сәйдәшнең җырлары да тынып кала. Яздырылганнарның байтагы югалтыла.

Күңелләргә уй салган Рашат Низами күпләрне харап иткән бер четерекле мәсьәләгә дә кагылып уза. «Озын телләр, тар күңелле көнчел адәмнәр Сәйдәшнең хәмер белән «дуслыгы» турында ясалма гайбәт, уйдырма чәчә, – ди. – Ләкин Сәйдәш банкет өстәлләре янында эчү-исерү өчен түгел, ә бәлки аралашу, сүз җилемен куерту өчен утыра. Бер чәркәне сәгатьләр буена йоткалап утыра ул. Мондый бәйрәм, күңел ачулар – аның өчен күтәренке бер ял вакыты».

Елъязмачы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында матәм барышында күзәтелгән аңлашылмаучанлыкны да искә төшерә. Өлкә комитеты вәкиле мәрхүмнең югары бүләкләрен чыгарырга тәкъдим итә. Шагыйрь Мөхәммәт Садри аңа: «Әсезнең аларны биргәнегез булдымы соң?» – дип каршы чыга. Сәйдәшне җирләгәндә, гәрчә Тукайны, Такташны соңгы юлга озаткандагы кебек, халык ташкыны урамга сыймаса да, җәмәгать транспорты йөрүдән туктаса да: «Ул аңа лаек түгел», – дип, кинохроника төшерергә килгән төркем дә борып җибәрелә. Ә соңрак композитор иҗаты буенча кандидатлык диссертациясе язуны тыючы табыла. «Аңа диплом эше дә бик җиткән», – дигән сүзләр әйтелә…

Китаптагы икенче әсәр – «Җыр һәм мылтык» исемле ике пәрдәлек драматик повесть. Монысы композитор Фәрит Яруллинга багышлана. Аның образын сәхнәдә 9 уенчы ача. Әмма тетрәндергеч бу драма, нишләптер, татар театрлары репертуарына кертелми. Югыйсә 27 яшьтә сугышка – үлемгә җибәрелгән сәнгать әһеле исеме мәңгеләштерүгә бик лаек. Моңа үз халкын өзелеп яраткан берәр режиссёрның игътибар юнәлтүе генә кирәк.

«Яшәүгә гимн». Монысы – поэма-рапсодия. Шагыйрь тарафыннан композитор, СССР халык артисты Рөстәм Яхинга (1921–1993) атап языла. Җиңел укыла, йөгерек теле үзенә ияртә, фикер үсеше төрле иҗтимагый-сәяси биеклекләргә алып менә. Ни дисәң дә, ул тудырган моңнар Ватан байрагына яшәү гимны булып чигелгән бит!

Журналист, язучы, шагыйрь Рашат Низаминең «Татар моңының өч йолдызы» китабын тыныч кына укып булмый. Аның сәхифәләре белән танышканда, үзеңнән-үзең милли сәясәт агышына килеп эләгәсең. Күренекле композиторларыбыз язган көйләрнең халык яшәешендә югалмаслык урын алуын сизәсең. Шуңа күрә сәләт ияләренең тормыш, иҗат юлларын белү, аның агышын мәгълүмат хәзинәсе белән баетып, тулыландырып тору хәерле.

Рашат Низами шулай ук шагыйрь булуын да исеннән чыгармый. Хисле, уйлы, фикерле әсәрләрен вакытлы матбугат аша халкыбызга даими тәкъдим итеп тора. Алар, бергә туплангач, китап булып та дөнья күрә. Укучылар кулына килеп кереп, күңелләрдә төрле фикерләр уята. Шагыйрь булырга хыялланган иҗатчылар өчен үрнәк – өлге булып тора.

Боларны истә тотып, Татарстан китап нәшрияты язучы, шагыйрь Рашат Низамины Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә кандидат итеп тәкъдим итә. Иҗатчының болай зурлануы бик табигый. Аның исән чагында болай зурлануы, танылуы хәерле.

Хәмзә БӘДРЕТДИНОВ,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе **Демидов** Алексей Иванович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының тышкы икътисади һәм мәдәни элемтәләрен үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле **Вәлиуллин** Ренат Нәкыйф улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Гайфуллин** Васил Габдулла улы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгы урынбасары **Игнатьева** Венера Алексеевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Җир төзелеше өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе **Шәйхиев** Рәис Рәйф улына **«Татарстан Республикасының атказанган җиртөзәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Ватаным Татарстан» редакциясе коллективы, әнисе

Әнүзә Әмирҗан кызы

вафат булу сәбәпле, хезмәттәшебез, язучы Марат Кәбиров һәм аның якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы, Сарман районы ветераннар (пенсионерлар) Советы рәисе

МИҢНЕГУЛОВ Нәҗип Мөҗип улының

вафат булуы сәбәпле, тормыш иптәше Рәшидә ханымның, балалары Наил, Камил, Айгөлнең, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Мәрхүмнең урыны оҗмахта булсын, гаиләсенә һәм якыннарына Ходай сабырлык бирсен.

Казан федераль университетының гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы коллективы, әнисе

ГАЛИЕВА Вәзирә Нурулла кызының

вакытсыз вафат булуы сәбәпле, кафедра доценты Җамалетдинова Гөлнара Фәндәс кызы һәм аның тормыш иптәше – Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, гомуми тел белеме һәм тюркология кафедрасы мөдире профессор Җамалетдинов Рәдиф Рифкать улының, туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

Илсур Гыймадетдинов

Илнар Закиров

Айназ Тимеров

Динар Кәримуллин

Рамил Синәкәев

Ренас Кәлимуллин

Раил Сәлахетдинов

Булат Мусин

Радик Сәлахов

Ранис Гыйлаҗетдинов

МУСА КАЗАНГА КАЙТТЫ

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Газетабыз турниры

Чаллы белән Әлмәт арасы тагын бер җиңүгә якынайды. Герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган бәйгенең быелгысын нефть башкаласы егетләре отты һәм сигезенче мәртәбә кубокка ия булдылар. «Алып килеп тә торасы булмаган икән», – диеште алар. Шәхси ярышта былтыргы җиңүчеләрдән бары өчесе генә үз титулын саклап кала алды.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Ак барс»та тәүге очрашу

Муса Җәлил бәйгесе башланган көнне Татарстанның Көрәш федерациясе президиум утырышын уздырды. Анда узган елга нәтиҗә ясадылар һәм киләчәктә ни эшлисе турында фикерләштеләр. Хәзерге вакытта республикада 10 меңгә якын кеше милли спорт төре белән шөгыльләнә. Районнарда исә хәлләр төрлечә. Әйтик, Балтач белән Кукмарада 700–800 көрәшче исәпләнә. Кем әйтмешли, эшли дә, бил алыша да беләләр. Шул ук вакытта ике ярышның берсенә исеме өчен генә килеп китүче районнар да бар. «Нәтиҗә булсын өчен, теләк белән мөмкинлекнең бергә туры килүе кирәк», – диде Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, федерация президиумы рәисе Марат Әхмәтов. Утырышта, көрәшне үстерү өчен, мәктәпләргә аерым мөнәсәбәт күрсәтү турында килештеләр. Район җирендәге эре авыл хуҗалыгы оешмаларын да җәлеп итү нияте бар. Марат Әхмәтов зур шәһәрләрдә дә көрәшкә ныклап алынырга вакыт җиткәнлеген әйтте. Бердән, авыл җирендә балалар саны кими. Икенчедән, саладан калага күчкән егетләрне дә югалтмыйсы иде.

Газетабыз турниры Казанда соңгы тапкыр 2006 елда узган иде. Чаллы, Әлмәт, Биектау, Зәй, Актаныш һәм Минзәләдә җәмгысы 15 бәйге узгач, быелгысы кабат Татарстан башкаласында оештырылды. Казанның көрәш үзәгенә әверелгән «Ак барс» комплексы үз тарихында тәүге мәртәбә Муса Җәлил бәйгесен – 45 командадан 350дән артык көрәшчене кабул итте. Әлбәттә, келәмгә һәрберсе җиңү өмете белән чыкты. Моннан ярты гасыр элек тә, хәзер дә шулай ул. Тик батыр калу һәркемгә бирелми. Ә 10 финалның алтысы чиста җиңү белән тәмамланды.

Яшь бара бит, егетләр

60 килолы егетләр ярышында икенче ел рәттән Кукмара егете Илсур Гыймадетдинов җиңү яулады. Быел ул финалда Чаллыдан Ришат Исхаковны отты. Илсур көндәшеннән 7 яшькә өлкәнрәк. Моңа ул үзе дә игътибар итте. «Яшь бара бит, акрынлап туктар вакыт якынлаша. Безнең категориядә яшь, җитез, егетләр бил алыша. Алар белән ярышу җиңел түгел», – диде 31 яшьлек Илсур.

65 килолы егетләр ярышында Чистайдан Илнар Закиров батыр калды. Муса Җәлил турнирында икенче мәртәбә җиңде ул. «Бик зур хезмәт нәтиҗәсе бу», – диде 24 яшьлек көрәшче. Финалда ул Шамил Локмановны (Теләче) чистага салды. Былтыргы җиңүче Илназ Миңмуллин (Балтач) – өченче урында.

70 килолы көрәшчеләр финалында Чаллыдан Айназ Тимеров белән Биектаудан Булат Юнысов очрашты. Бик озак бил алыштылар, ахырда Булат өч кисәтү алып, җиңелергә мәҗбүр булды. Узган ел икенче урынны алган 23 яшьлек Айназ исә Казан келәмендә батыр исемен яулады. «Өченче, икенче булдым, быел, ниһаять, оттым. Елыйсы килә хәтта», – диде яшь батыр. Дөрес, аның үзен дә чистага салдылар. Айназның тренеры Илнур Хәйбуллинга сөенеченнән ни эшләсә дә килешә.

75 килолы егетләр финалында инде икенче ел рәттән Рафаэль Кәлимуллин чыгыш ясый. Дөрес, былтыр ул Түбән Кама данын якласа, быел Әлмәт өчен бил алышты. Ә без аның Менделеевск районындагы Камай авылында көрәш дөньясына ике батыр үстереп биргән Кәлимуллиннар гаиләсендә дөньяга килгәнен дә беләбез. Абыйсы Ренас рекордка омтылса, Рафаэльгә әлегә Муса Җәлил турнирында җиңү бәхете елмаймый. Былтыр ул Чаллыдан Ленар Садыйковка, быел исә Лаештан Динар Кәримуллинга оттырды. «Бу бәйгедә икенче тапкыр җиңүемә бик сөендем. Рафаэльгә Татарстан чемпионатында җиңелгән идем. Менә җавабын кайтардым», – диде 26 яшьлек Динар.

Танылган батыр Ильяс Галимов истәлегенә гамәлгә куелган һәм финал алышларында иң яхшы алым күрсәткән көрәшчегә тапшырылучы бүләккә Әлмәт егете Рамил Синәкәев лаек булды.
– Ильяс үзе дә бик матур көрәште, матур алымнар күрсәтте. Минем өчен остаз да, легенда да иде ул. Әлбәттә, аңа охшарга тырышабыз. Әмма Ильяска җитәргә бик ерак әле безгә, – диде ул.

Ренас өскә карый

80 килолы егетләр ярышының ярымфиналында Әлмәттән Рамил Синәкәев белән Муса Җәлил бәйгесенең 5 мәртәбә җиңүчесе, Теләче өчен бил алышучы башкорт егете Артур Зөлкарнәев очрашты. Әллә атна-ун көн элек кенә өйләнеп йөргәнгә, әллә башка сәбәп аркасында Артур Рамилгә каршылык күрсәтә алмады. Синәкәев исә финалда кызган баштан Ринат Шәйхетдиновны (Чаллы) чистага атып бәрде. «Әлеге турнирда көчсез көндәшләр булмый. Финалга таба барган саен авыррак. Иң зур рәхмәтем – әтигә. Беләм, ул да минем белән горурлана», – диде өченче җиңүен яулаган 29 яшьлек Рамил.

Узган ел 80 килолылар ярышында Теләчедән Ренас Кәлимуллин җиңү яулаган иде. Быел ул 85ләр арасында бил алышты һәм финалда Лаештан Ранис Галимуллинны отты. Бу – Ренасның газетабыз бәйгесендә җиденче уңышы. Димәк, аңа «иң-иң»нәр сафына керергә дә күп калмады. «Бу җиңү белән тагын бер баскычка күтәрелдем дип уйлыйм. Бер башлагач, куып тотарга кирәк инде рекордчыларны», – ди ул. Ренасның көрәшен күрергә бу юлы да туганнары җыелып килгән иде.

90 килога кадәрге авырлык үлчәвендә финалда Кукмарадан Раил Сәлахетдинов белән Чаллыдан Илнар Галимов очрашты. Икесе дә – былтыргы җиңүчеләр. Озак тартыштылар, үзләренә дә, хөкемдарларга да авырга туры килде. Ахыр чиктә Раил җиңде һәм гадәттәгечә хисләнеп, тамашачының күңелен күреп алды. Бу егеткә беркем дә битараф кала алмый. «Бик авыр булды, Аллаһы Тәгалә бар ул, – диде җиңүче фәлсәфәгә бирелеп. – Минем җиңү белән килешмәүләргә ни әйтимме? Эт өрә, кәрван бара. Без дә алга таба барабыз. Муса Җәлил бәйгесе – минем турнир инде ул. Дүртенче финал, өченче җиңүем».

«Мин алардан киммени?»

Быел, ниһаять, Булат Мусинга да бәхет елмайды. Көрәш дөньясының келәмнән читтә иң танылган вәкиленә әверелгән, ярыш карарга йөрүче туташлар санын арттырган егет Муса Җәлил бәйгесендә дүртенче җиңүен яулады. 100 килолы егетләр финалында ул Чистай районы өчен бил алышкан Айнур Сыртаевны чистага салды. «Минем өчен җан аткан бар кешегә рәхмәт. Иң рәхәт хисләр кичерәм. Сүзләрен дә табып булмый хәтта», – диде Яңа Чишмә районының Чертуш авылында туып-үскән егет.

Раил Нургалиев – бил алышучылар арасында газетабыз бәйгесендә иң күп уңышка ирешкән егет. Теләче батырының 9 җиңүе бар. Турнир алдыннан журналистлар белән очрашуда ул әле тагын берничә ел көрәшергә җыенганын, җиңәргә өметләнгәнен әйтте. Әмма Радик Сәлаховның да җиңәсе килә. Авырлыгы 130 килодан артмаган көрәшчеләр ярышында алар бу юлы икенче әйләнештә үк очрашты һәм Раилгә тамашачылар арасына күчеп утырырга туры килде. Радик исә ярымфиналда Муса Галләмовны отты, финалда Руслан Газизуллинны чистага салды. Көрәш ярышларында һәрвакыт җиңүчеләр сафында йөрсә дә, Муса Җәлил турнирында инде 6 ел батыр калганы булмаган икән Сәлаховның. Бу юлы көчле көндәшләренең барысын да отып, җиңү яулады ул.

Раил исә бирешергә җыенмый. «Яхшылап шөгыльләнсәм, 130да да көрәшә алачакмын дип уйлыйм. Алла боерса, әзерләнергә кирәк. Җиңәсе килә әле минем», – диде ул. Сүз уңаеннан, татар көрәшендә 100 һәм 130 килолы үлчәү категорияләре арасына тагын берне өстәү фикерләре еш ишетелә башлады.

«Мин алардан киммени?» Булат белән Радикның көндәшләрен чистага салганын күреп торган Ранис Гыйлаҗетдинов шулай уйлаган, ахрысы. Чаллы егете авыр үлчәүдәге финалда Арчадан Альберт Ситдыйковка бер мөмкинлек тә калдырмады һәм быелгы турнирга матур итеп нокта куйды.

Җиңүче команда кубогы исә икенче ел рәттән Әлмәт егетләренә насыйп булды. Сигезенче уңышлары бу аларның. Тагын бер мәртәбә отсалар, Чаллы командасын куып тотачаклар.

Быелгы бәйгенең җиңүчеләре

60 кило
I урын – Илсур Гыймадетдинов (Кукмара).
II урын – Ришат Исхаков (Чаллы).
III урын – Алексей Абрамов (Лаеш).
III урын – Раил Хәбибрахманов (Мамадыш).

65 кило
I урын – Илнар Закиров (Чистай).
II урын – Шамил Локманов (Теләче).
III урын – Илназ Миңмуллин (Балтач).
III урын –Раббани Нургалиев (Актаныш).

70 кило
I урын – Айназ Тимеров (Чаллы).
II урын – Булат Юнысов (Биектау).
III урын – Илназ Рамазанов (Тукай).
III урын – Илдар Закиров (Лаеш).

75 кило
I урын – Динар Кәримуллин (Лаеш).
II урын – Рафаэль Кәлимуллин (Әлмәт).
III урын – Илназ Шәмсиев (Баулы).
III урын –Инсаф Кәримуллин (Арча).

80 кило
I урын – Рамил Синәкәев (Әлмәт).
II урын – Ренат Шәйхетдинов (Чаллы).
III урын – Артур Зөлкарнәев (Теләче).
III урын –Илдар Гыйниятуллин (Теләче).

85 кило
I урын – Ренас Кәлимуллин (Теләче).
II урын – Ранис Галимуллин (Лаеш).
III урын – Айрат Сәмигуллин (Әлмәт).
III урын –Ринас Садаров (Яңа Савин).

90 кило
I урын – Раил Сәлахетдинов (Кукмара).
II урын – Илнар Галимов (Чаллы).
III урын – Илсур Сафин (Лаеш).
III урын –Нәфис Галиев (Кукмара).

100 кило
I урын – Булат Мусин (Яңа Савин).
II урын – Айнур Сыртаев (Чистай).
III урын – Айдар Алтынбаев (Әлмәт).
III урын –Руслан Рафыйков (Балтач).

130 кило
I урын – Радик Сәлахов (Әлмәт).
II урын – Руслан Газизуллин (Лаеш).
III урын – Муса Галләмов (Лаеш).
III урын – Турал Азимов (Чистай).

130+
I урын – Ранис Гыйлаҗетдинов (Чаллы).
II урын – Альберт Ситдыйков (Арча).
III урын – Фәрхат Фәйзуллин (Теләче).
III урын –Фәнил Тимергалиев (Лаеш).

Командалар беренчелеге

1. Әлмәт
2. Лаеш
3. Чаллы/Комсомол
4. Теләче
5. Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары
6. Кукмара
7. Арча
8. Чистай
9. Мамадыш
10. Балтач

РӘХМӘТ СҮЗЕ

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә 59 нчы мәртәбә уздырылган көрәш бәйгесен оештыруда төп эшне башкарган Татарстанның Көрәш федерациясенә, Спорт министрлыгына, турнирның ачылу тантанасын әзерләүдә ярдәм күрсәткән өчен Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры коллективына, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенә зур рәхмәтен җиткерә.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7101 данә
Гомуми тираж – 17132 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 239

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+